КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 апрель г.Казань № 223

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген оештыру һәм тикшереп тору тәртибен раслау турында

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы һәм «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе;

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген оештыру һәм тикшереп тору тәртибе.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 18 июнь, 501 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 974 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеге өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенщ үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 09 сентябрь, 807 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 8 апрель, 223 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе

1. Әлеге Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләр билгели (алга таба - төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)).

2. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) әлеге Тәртип нигезендә «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясында (66-ТРЗ номерлы Закон) күрсәтелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары һәм аерым муниципаль берәмлекләрдә, аларга карата 66-ТРЗ номерлы Закон гамәлдә булуы туктатып торылганТатарстан Республикасы дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба - Инспекция) тарафыннан (алга таба - контроль органнары) гамәлгә ашырыла.

3. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелегек) Инспекциянең түбәндәге вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла: Инспекция башлыгы, Инспекция башлыгы урынбасарлары, өлешле төзелешне контрольдә тоту бүлеге башлыгы (алга таба - бүлек), бүлекнең әйдәүче консультанты, бүлекнең өлкән белгече.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

4. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларга, шул исәптән төзүчеләргә (алга таба - өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар, төзүчеләр) карата гамәлгә ашырыла.

5. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда (алга та-

ба - 214-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында (алга таба - күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнар) билгеләнгән өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын, мәҗбүри таләпләрне җәлеп итүче затлар тарафыннан үтәү тора.

6. Юридик затларга төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга, тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 294-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

7. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруның төп бурычлары - өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм кабул итү.

8. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үтәүне планнан тыш тикшерүләр оештыру һәм уздыру;

өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү;

төзүче оешма белән бәйләнешкә кермичә тикшерү чаралары оештыру һәм үткәрү;

өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны кабул итү;

9. Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен планнан тыш тикшерүләр оештыру һәм үткәрү 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 пунктында билгеләнгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

10. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затлар тарафыннан 294-ФЗ номерлы Федераль законның $8^2$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан

мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы карары белән расланган Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Төзүче оешма белән үзара бәйләнешкә кермичә тикшерү чараларына түбәндәгеләр керә:

күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрнең квартал саен хисаплылыгына анализ, шул исәптән төзелеш проектларын һәм шартнамәләр буенча йөкләмәләрне гамәлгә ашыруның якынча графикларын, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен (алга таба - төзүченең кварталлык хисабы) башкару;

күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашуга карата законнарның мәҗбүри таләпләрен төзүче тарафыннан мәгълүматны анализлау юлы белән үтәүне мониторинглау, аны ачу бурычы күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнар нигезендә төзүчегә йөкләнгән;

күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турындагы законнарның мәҗбүри таләпләрен төзүче тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мәгълүматны урнаштыруның составына, тәртибенә, ысулларына, срокларына һәм ешлыгына мониторинг ясау.

12. Төзүчеләр белән үзара хезмәттәшлексез контрольлек чаралары контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә контрольдә тотучы органнар җитәкчесе яисә җитәкче урынбасары тарафыннан раслана торган мондый чараларны үткәрүгә биремнәр нигезендә уздырыла.

13. Төзүче оешманың квартал саен хисаплылыгын анализлау түбәндәге нәтиҗәләрне формалаштыру максатларында гамәлгә ашырыла:

төзүче оешма тарафыннан төзүченең квартал саен хисаплылыгын һәм аның составына таләпләрне контрольлек итүче органга тапшыру срокларын үтәү;

өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын төзүче оешма тарафыннан максатчан файдаланмау яисә аларның булмавы турында;

төзүче оешма үз эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативларын үтәү турында;

өлешле төзелештә катнашучылар алдында төзүче ошема тарафыннан шартнамә йөкләмәләрен үтәү срокларын үтәү турында;

төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын төзүче оешма тарафыннан үтәү турында.

14. Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турындагы законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган очракта, төзүчеләр белән үзара багланышларсыз чаралар уздырганда, тикшереп тору органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары үз

компетенцияләре чикләрендә мондый хокук бозуларны булдырмау чараларын күрә. Төзүче оешманың квартал саен хисаплылыгын анализлау нәтиҗәләре буенча тикшереп торучы органнарның вәкаләтле вазыйфаи затлары язма рәвештә контроль органнары җитәкчесенә яисә җитәкчесенең урынбасарына планнан тыш тикшерүне билгеләү турында карар кабул итү өчен ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүмат белән дәлилләнгән күзаллау җибәрә.

15. Контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затларының хокуклары һәм бурычлары 294-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 214-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән.

Контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары тикшерүләр уздырганда 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә һәм бурычларны үтәргә тиеш.

Контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

16. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда, контроль органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурасы органнары, үз-үзен җайга салучы оешмалар, экспертлар, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар, гражданнар белән аларның мөрәҗәгатьләре буенча хезмәттәшлек итә.

17. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда административ процедураларның сроклары һәм эзлеклелеге контроль органнары тарафыннан расланган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентлары белән билгеләнә.

18. Тикшереп торуны гамәлгә ашыручы контроль органнары вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

19. Контроль органнары «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзләренең рәсми сайтларында төзүче эшчәнлеген үткәрелгән тикшерүләр турында, моңа керү мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән чикләнгән белешмәләрдән тыш, мәгълүматны, шулай ук төзүчене, аның вазыйфаи затларын 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозган өчен административ җаваплылыкка тарту турында контроль органнарының закон көченә кергән карарлары хакында белешмәләрне урнаштыралар.